**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» июль, 2025 ел № 412-п

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына идентификация номерларын бирү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 февралендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 08 декабрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Автомобиль юлларына идентификация номерларын бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2007 елның 7 февралендәге 16 номерлы боерыгы, «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына идентификация номерларын бирү тәртибен раслау турында» 2023 елның 15 декабрендәге 965 номерлы Башкарма комитет карары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә.

1. Кушымта нигезендә идентификация номерларын гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына бирергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Питрәч районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Р. Дәүләтханов

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
кушымта

Питрәч муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юллары исемлеге.

| № п.п. | Кадастр юл номеры/исеме | Катего-рия | Озынлыгы, км | | | | | Автомобиль автомобиль юлларының идентификация номерлары юллар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлыгы | шул исәптән | | | | |
| | | | | Цемент - бетон | Асфальт - бетон | Щебень, гравий | грунт | |
| 1 | 16:33:211103:229 | V | 3 | | | | 3 | 92-248-000 МСТ МР 92Н-004 |